ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» мая 2021 ел № 136

Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 15 мартындагы 450-р номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасының башка бюджетара трансфертлары исәбеннән Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге бюджетына башка бюджетара трансферт бирү турында

«Кристалл-НКУ» сериясенең су әзерләү контейнеры станциясен сатып алу өлешендә халыкны су белән тәэмин итү өчен җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында 2021 елның 15 мартындагы 450-р номерлы карарын, «Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өлешендә финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 июлендәге 561 номерлы карарын, «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы арасында төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру өлешендәТатарстан Республикасы бюджетыннан җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансферт бирү турында төзелгән килешүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. «Кристалл-НКУ» сериясендәге контейнер станциясен сатып алу өлешендә халыкны су белән тәэмин итү өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы

күләмдә финанслау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.03.20021 ел, № 450-р карары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан 3 109 256,0 сум күләмендә башка бюджетара трансферт бирергә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге бюджетының чыгым өлешен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.03.2021 номерлы карары белән каралган Татарстан Республикасының бюджетара трансфертлары исәбеннән 2021 елга арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге бюджетына төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслауга башка бюджетара трансферт бирү турында килешү төзергә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге бюджетына төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансферт бирү турында Килешү (кул куелган), "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә http://pravo.tatarstan.ru.

5. «Кристалл-НКУ» сериясендәге контейнер станциясен сатып алу өлешендә Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 15 мартындагы 450-р номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасының башка бюджетара трансфертлары исәбеннән Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге бюджетына башка бюджетара трансферт бирү турында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 07.05.2021 № 124 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

7. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 16 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

8. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**